МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

26 сентябрь 2017 ел

№ М 363

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең террорчылыкка каршы комиссиясе нигезләмәсен, эш регламентын һәм составын раслау турында

Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау системасының нәтиҗәлелеген арттыру максатында, «Экстремистлык эшчәнлегенә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон, «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең террорчылыкка каршы комиссиясе (алга таба – комиссия) турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) комиссиянең эш регламентын, 2 нче кушымтада каралганча;

3) комиссия составын, 3 нче кушымтада каралганча.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең террорчылыкка каршы комиссиясен оештыру турында» 2007 елның 30 гыйнварындагы 29 номерлы карары;

2) шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең террорчылыкка каршы комиссиясе составын раслау турында» 2013 елның 14 октябрендәге М 639 номерлы карары;

3) шәһәр Хакименең «Аерым комиссияләр составына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 11 декабрендәге М 759 номерлы карарының 2 пункты;

4) шәһәр Хакименең «Террорчылыкка каршы комиссия составына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 17 февралендәге М 113 номерлы карары;

5) шәһәр Хакименең «Террорчылыкка каршы комиссия составына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 25 апрелендәге М 248 номерлы карары;

6) шәһәр Хакименең «Аерым комиссияләр составына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 октябрендәге М 650 номерлы карары;

7) шәһәр Хакименең «Террорчылыкка каршы комиссия составына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 1 октябрендәге М 284 номерлы карарының 2 пункты;

8) шәһәр Хакименең «Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең террорчылыкка каршы комиссиясен оештыру турында» 2007 елның 30 гыйнварындагы 29 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 21 гыйнварындагы М 19 номерлы карары.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреевага һәм Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Хакименең
2017 елның 26 сентябрендәге
М 363 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
террорчылыкка каршы комиссиясе турында
нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең террорчылыкка каршы комиссиясе (алга таба – комиссия) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә, «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 16 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законның 5.2 статьясында каралган террорчылыкка каршы тору өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен тормышка ашыру эшчәнлеген оештыру максатында оештырылган коллегиаль орган булып тора.

2. Комиссиянең кыскартылган исеме - ТКК.

3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм норматив хокукый актларына, муниципаль хокукый актларга, Террорчылыкка каршы милли комитет һәм Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссия карарларына, шулай ук әлеге нигезләмәгә таянып эш итә.

4. Комиссия рәисе булып шәһәр Хакиме тора.

5. Комиссиянең персональ составы шәһәр Хакиме карары белән раслана. Аның составына муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарның бүлекчәләре һәм җитәкчеләре, вәкилләре, шулай ук Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары керә.

Вазыйфалар буенча комиссия составына керүче затлар белән беррәттән, комиссия рәисе карары буенча аның составына муниципаль берәмлекнең террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның нәтиҗәләрен һәм билгеләрен минимальләштерү һәм бетерү эшчәнлегендә катнашучы башка дәүләт органнары, оешмалары һәм иҗтимагый берләшмәләре җитәкчеләре (вәкилләре) керергә мөмкин.

6. Комиссиянең төп бурычы булып Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма

хакимияте органнарының бүлекчәләре (вәкилләре) белән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның чагылышы нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү буенча үзара хезмәттәшлеген оештыру тора.

7. Комиссия түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның чагылышы нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү өлкәсендә муниципаль программаларны эшләүне һәм тормышка ашыруны оештыру;

2) террорчылыкның асылын һәм аның иҗтимагый куркынычлылыгын аңлату, шулай ук гражданнарда террорчылык идеологиясен кабул итмәү буенча мәгълүмати-пропаганда чаралары уздыруны тәэмин итү, шул исәптән мәгълүмати материаллар, басма продукция тарату, аңлату эше һәм башка чаралар үткәрү юлы белән;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның чагылышы нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү буенча җирле үзидарә органнары катнаша торган чаралар үтәлешен координацияләү;

4) муниципаль милектәге яки җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан башка объектларның террорчылыктан саклану дәрәҗәсен арттыру чараларын эшләү;

5) Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының террорчылыкны профилактикалауда, шулай ук аның чагылышы нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яки) бетерүдә катнашу мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына тәкъдимнәр әзерләү;

6) җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының бүлекчәләре (вәкилләре) белән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның чагылышы нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм бетерү буенча үзара хезмәттәшлеген оештыру өчен кирәкле башка чараларны гамәлгә ашыру.

8. Комиссия үз компетенциясе чикләрендә һәм билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының бүлекчәләре (вәкилләре) белән террорчылыкны профилактикалау, аның чагылышы нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү буенча үзара хезмәттәшлеген оештыруга һәм камилләштерүгә кагылышлы карарлар кабул итәргә, шулай ук аларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

2) Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының бүлекчәләреннән (вәкилләреннән), җирле үзидарә

органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, оешмалардан (милек формаларына бәйсез рәвештә) һәм вазыйфаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга;

3) террорчылыкны профилактикалауга, аның чагылышы нәтиҗәләрен минимальләштерүгә һәм (яки) бетерүгә кагылышлы мәсьәләләрне өйрәнү өчен, шулай ук комиссиянең тиешле карарлары проектларын әзерләү өчен эш органнары (эш төркемнәре) булдырырга;

4) комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары бүлекчәләренең, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын һәм белгечләрен, шулай ук аларның җитәкчеләре белән килештереп, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләрен җәлеп итәргә;

5) Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссия карарын таләп итә торган мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә.

9) Комиссия үз эшен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык актын яки аны кылуның турыдан-туры куркыныч тудыручы гамәлләрен туктату буенча беренче чираттагы чараларны гамәлгә ашыру өчен формалаштырылган оператив төркем белән үзара хезмәттәшлектә төзи.

10. Комиссия үз эшчәнлеген, шәһәр Хакиме карары белән расланган регламентка туры китереп, план нигезендә гамәлгә ашыра.

11. Комиссия, Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссия тарафыннан билгеләнә торган форма буенча, яртыеллык һәм бер еллык эшчәнлеге йомгаклары буенча Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссиягә хәбәр итә.

12. Үткәрелгән утырышлар йомгаклары буенча комиссия материалларны Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссиягә тапшыра.

13. Комиссия секретаре:

1) комиссия аппараты эшен оештыра;

2) комиссиянең эш планнары һәм комиссия эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисаплар проектын эшли;

3) комиссия утырышларын әзерләүне һәм уздыруны тәэмин итә;

4) комиссия карарлары үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

5) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылыкны профилактикалау өлкәсендәге хәлләрне үстерүгә йогынты ясый торган иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисадый һәм башка процесслар турында мәгълүмат җыю, туплау, гомумиләштерү һәм анализлау, мәгълүмати материаллар әзерләү эшен оештыра;

6) комиссиянең Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссия һәм аның аппараты белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

7) комиссиянең эш органнары эшчәнлеген тәэмин итә;

8) комиссия эшен оештыра һәм алып бара.

Комиссия әгъзалары бурычлы:

1) беркетмә карары белән расланган комиссия, комиссия рәисе карарлары яки комиссия әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә комиссия каравына кертелә торган мәсьәләләр әзерләүне оештырырга;

2) үз вазыйфаи вәкаләтләре кысаларында комиссия карарларын үтәүне оештырырга;

3) комиссия эшчәнлеген регламентлаштыра торган хокукый актлар таләпләрен үтәргә;

4) вәкиле булып торган органдагы компетенциясе чикләрендә, күрсәтелгән органның комиссия һәм аның секретаре белән үзара хезмәттәшлеген оештыру өчен җаваплы вазыйфаи затны яки бүлекчәне билгеләргә.

Комиссия әгъзалары хокуклы:

1) комиссия утырышларында чыгыш ясарга, комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә һәм, кирәк булган очракта, әлеге мәсьәләләр буенча тавыш бирүне үткәрүне таләп итәргә;

2) комиссия утырышларында тавыш бирергә;

3) комиссия эшчәнлегенә турыдан-туры кагыла торган документлар һәм материаллар белән танышырга;

4) комиссия секретаре белән хезмәттәшлек итәргә;

5) билгеләнгән тәртиптә комиссия рәисе белән килештереп, Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының бүлекчәләре, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар хезмәткәрләрен һәм белгечләрен комиссия эшчәнлегенә бәйле экспертиза, аналитик һәм башка эшкә җәлеп итәргә;

6) комиссия карары белән килешмәгән очракта, аерым фикерне язма рәвештә бәян итәргә, ул комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга һәм аның карарына теркәлергә тиеш.

16. Комиссия үз исеме булган бланкка ия.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары

Ф.И. Андреева

Шәһәр Хакименең
2017 елның 26 сентябрендәге
М 363 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
террорчылыкка каршы комиссиясе
регламенты

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге регламент, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең террорчылыкка каршы комиссиясе турындагы нигезләмәдә беркетелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең террорчылыкка каршы комиссиясе (алга таба – комиссия) эшчәнлеген оештыруның гомуми кагыйдәләрен билгели.

2. Комиссиянең төп бурычы һәм функциясе муниципаль берәмлектә террорчылыкка каршы комиссия турында нигезләмәдә бәян ителде.

2 бүлек. Комиссия эшен планлаштыру һәм оештыру

3. Комиссия үз эшчәнлеген комиссиянең еллык эш планы (алга таба – комиссиянең эш планы) нигезендә гамәлгә ашыра.

4. Комиссиянең эш планы комиссия эшчәнлеген планлаштыру буенча Террорчылыкка каршы милли комитет һәм Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссия (алга таба – Татарстан Республикасында ТКК) аппараты киңәшләрен исәпкә алып, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һәм Татарстан Республикасында террорчылыкны профилактикалау өлкәсендә барлыкка килгән шартлардан чыгып әзерләнә, комиссия утырышында карап тикшерелә һәм комиссия рәисе тарафыннан раслана.

5. Комиссия утырышлары комиссиянең эш планы нигезендә кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Кирәк булган очракта, Татарстан Республикасында ТКК рәисе һәм комиссия рәисе карарлары буенча комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

6. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча комплекслы карарлар әзерләү өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә оператив төркем әгъзалары катнашында комиссия утырышлары үткәрелергә мөмкин.

Комиссиянең эш планы проектына тәкъдимнәр, планлаштырыла торган чор башланырга ике айдан да соңга калмыйча яисә комиссия рәисе

тарафыннан билгеләнгән срокларда, язма рәвештә комиссия секретарена кертелә.

Комиссия утырышында мәсьәләләрне карау буенча тәкъдимнәрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) мәсьәләнең исеме һәм аны комиссия утырышында карап тикшерү кирәклеген кыскача нигезләү;

2) тәкъдим ителә торган карарның формасы һәм эчтәлеге;

3) мәсьәләне әзерләү өчен җаваплы орган исеме;

4) башкаручылар исемлеге;

5) комиссия утырышында карап тикшерү датасы.

Комиссиянең эш планы проектына комиссия утырышында каралуны кертергә тәкъдим ителгән очракта, карар карар орган компетенциясенә керми, аны тәкъдим итә торган орган инициаторына тәкъдим итүче мәсьәләне алдан килештерергә кирәк.

Комиссиянең эш планы проектына тәкъдимнәр комиссия әгъзаларына өстәмә эшләү өчен комиссия секретаре тарафыннан җибәрелергә мөмкин. Комиссия әгъзаларының бәяләмәләре һәм кертелгән тәкъдимнәр буенча башка материаллар, әгәр теркәп җибәрелә торган документта башкача килешенмәгән булса, аларны алган көннән башлап бер айдан да соңга калмыйча, комиссия секретарена тапшырылырга тиеш.

8. Комиссия секретарена кергән тәкъдимнәр нигезендә комиссиянең эш планы проекты төзелә, ул комиссия рәисе белән килештереп, агымдагы елның соңгы утырышында фикер алышу һәм раслау өчен чыгарыла.

9. Комиссиянең расланган эш планы комиссия секретаре тарафыннан комиссия әгъзаларына һәм ТР ТКК аппаратына җибәрелә.

10. Комиссиянең эш планына үзгәрешләр кертү турындагы карар, карап тикшерүгә кертелгән мәсьәләне әзерләү өчен җаваплы комиссия әгъзасының нигезле язмача тәкъдиме буенча, комиссия рәисе тарафыннан кабул ителә.

11. Комиссия утырышларында өстәмә (планнан тыш) мәсьәләләрне карап тикшерү ТРда ТКК рәисе тәкъдиме һәм комиссия рәисе карары буенча гамәлгә ашырыла.

## 3 бүлек. Комиссия утырышларын әзерләү тәртибе

12. Комиссия әгъзалары, Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының башка бүлекчәләре, Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарының һәм комиссия утырышларында карап тикшерү өчен тиешле материаллар әзерләү йөкләнгән оешмаларның вәкилләре, комиссия эше планы нигезендә әлеге утырышларны әзерләүдә катнаша һәм материалларның сыйфаты һәм үз вакытында тапшырылуы өчен шәхси җаваплылыкка ия.

13. Комиссия секретаре Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, Татарстан

Республикасы башкарма хакимияте органнарының бүлекчәләре, Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнары һәм комиссия утырышына материаллар әзерләүдә катнашучы оешмалар вәкилләренә оештыру һәм методик ярдәм күрсәтә.

Комиссия утырышының көн тәртибе проекты чираттагы утырышка әзерлек процессында төгәлләштерелә һәм Комиссия рәисе белән Комиссия секретаре тарафыннан килештерелә. Утырышның көн тәртибе турыдан-туры утырышта комиссия карары белән раслана.

15. Комиссия каравына кертелә торган мәсьәләләрне әзерләү өчен, комиссия рәисе карары белән комиссия әгъзалары, җирле үзидарәнең кызыксынучы органнары вәкилләре, комиссия секретаре, шулай ук экспертлар (килешү буенча) арасыннан комиссиянең эш төркемнәре төзелергә мөмкин.

16. Комиссия утырышына материаллар, утырышны үткәрү датасына кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, комиссия секретарена тапшырыла һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) карап тикшерелә торган мәсьәлә буенча аналитик белешмә;

2) төп докладчы чыгышы тезислары;

3) карар пунктларын башкаручыларны һәм аларны башкару срокларын күрсәтеп, карап тикшерелә торган мәсьәлә буенча карар проекты;

4) карар проектын кызыксынган органнар белән килештерү материаллары;

5) булган очракта, тәкъдим ителгән проект буенча аерым фикерләр.

Комиссия утырышларында карап тикшерү өчен материалларның үз вакытында әзерләнүен һәм тапшырылуын контрольдә тотуны комиссия секретаре гамәлгә ашыра.

18. Материаллар әлеге регламентта билгеләнгән срокта тапшырылмаган яки алар әлеге регламентны бозып тапшырылган очракта, мәсьәлә карап ткшерүдән алынырга яисә карап тикшерү өчен башка утырышка күчерелергә мөмкин.

19. Булачак утырышның көн тәртибе, комиссиянең беркетмә карары проекты тиешле материаллар белән бергә, утырышны үткәрү көненә кадәр 7 эш көненнән дә соңга калмыйча, комиссия секретаре тарафыннан комиссия рәисенә тапшырыла.

Утырышның комиссия рәисе тарафыннан хупланган көн тәртибе, беркетмә карары проекты һәм тиешле материаллар, утырышны үткәрү датасына кадәр 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, комиссия әгъзаларына һәм утырышта катнашучыларга җибәрелә.

21. Утырышның көн тәртибе, беркетмә карары проекты һәм тиешле материаллар таратылган комиссия әгъзалары һәм утырышта катнашучылар, кимчелекләр һәм тәкъдимнәр булган очракта, утырышны үткәрү датасына кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, аларны язма рәвештә комиссия секретарена тапшыралар.

22. Комиссия карарларын тормышка ашыру өчен муниципаль хокукый акт кабул итү таләп ителгән очракта, комиссия утырышына материалларны әзерләү белән бер үк вакытта билгеләнгән тәртиптә муниципаль хокукый актларның тиешле проектлары эшләнә һәм килештерелә.

23. Комиссия секретаре, утырышны үткәрү датасына кадәр 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, комиссия әгъзаларына һәм утырышка чакырылган затларга комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә.

24. Комиссия әгъзалары, комиссия утырышын үткәрү датасына кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча, үзләренең катнашуы яки утырышта катнашмау сәбәпләре турында комиссия рәисенә мәгълүмат бирәләр. Комиссиянең җитди сәбәпләр (авыру, командировка, отпуск) аркасында булмаган әгъзалары исемлеге комиссия рәисенә тапшырыла.

25. Комиссия утырышларына Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының бүлекчәләре, Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнары җитәкчеләре, шулай ук карап тикшерелә торган мәсьәләгә турыдан-туры мөнәсәбәте булган башка органнар һәм оешмалар җитәкчеләре чакырылырга мөмкин.

26. Комиссия утырышына чакырылучы затларның составы тикшерелә торган мәсьәләләрне әзерләү өчен җаваплы органнарның һәм оешмаларның тәкъдимнәре нигезендә комиссия секретаре тарафыннан төзелә һәм, утырыш өчен документлар пакеты белән бергә, алдан ук комиссия рәисенә җиткерелә.

## 4 бүлек. Комиссия утырышларын үткәрү тәртибе

27. Комиссия утырышлары комиссия рәисе тарафыннан яисә аның кушуы буенча комиссия секретаре тарафыннан чакырыла.

28. Комиссия утырышларында катнашу өчен килгән затлар комиссия секретаре тарафыннан теркәлә.

29. Комиссия утырышында аның әгъзаларының булуы мәҗбүри. Комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен башка затларга тапшырырга хокуксыз.

Комиссия әгъзасы утырышта катнаша алмаган очракта, ул бу хакта комиссия рәисенә алдан ук хәбәр итәргә һәм, кирәк булганда, аның вазыйфаларын башкаручы затның утырышта (киңәшләшү тавышы хокукы белән) булу мөмкинлеген килештерергә тиеш.

30. Карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда, комиссия әгъзалары утырышта бертигез хокукларга ия.

31. Комиссия утырышы, анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала.

32. Утырышлар комиссия рәисе яисә аның кушуы буенча, аның урынбасары рәислегендә уза.

Комиссия рәисе:

а) комиссия утырышын алып бара;

б) комиссия утырышының көн тәртибе мәсьәләләре буенча фикер алышуны оештыра;

в) комиссия әгъзаларына, шулай ук чакырылган затларга чыгыш ясау өчен сүз бирә;

г) тавыш бирүне һәм тавышларны санауны оештыра, тавыш бирү нәтиҗәләрен игълан итә;

д) комиссия әгъзалары һәм чакырылган затлар тарафыннан әлеге регламент нигезләмәләренең үтәлешен тәэмин итә;

е) тавыш бирүдә катнашып, иң соңыннан тавыш бирә.

33. Комиссия утырышларының көн тәртибе мәсьәләләре буенча докладлар белән комиссия әгъзалары, чакырылган затлар яисә аерым очракларда, комиссия рәисе белән килештереп, комиссия әгъзалары тарафыннан вәкаләтләнгән затлар чыгыш ясый.

34. Комиссия утырышы регламенты утырышка әзерләнгәндә билгеләнә һәм турыдан-туры утырышта комиссия карары белән раслана.

35. Тавыш биргәндә комиссия әгъзасы бер тавышка ия һәм шәхсән тавыш бирә. Комиссия тарафыннан тәкъдим ителә торган карар белән килешмәгән комиссия әгъзасы күрсәтелгән карар кабул ителә торган комиссия утырышында беркетмәгә кертелә торган аерым фикерен комиссия әгъзаларына җиткерергә хокуклы. Язма рәвештә бәян ителгән аерым фикер комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлә.

36. Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч була.

37. Комиссия рәисе тарафыннан игълан ителгән тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә.

38. Комиссиянең ябык утырышларын үткәргәндә (аерым мәсьәләләр буенча ябык фикер алышканда) материаллар әзерләү, утырышка кертү, стенографикацияләү, беркетмәләрне һәм кабул ителә торган карарларны рәсмиләштерү яшеренлек режимын үтәп гамәлгә ашырыла.

39. Дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардан торган материаллар, утырыш алдыннан теркәлгән вакытта реестрда имза куйдырып, комиссия әгъзаларына тапшырыла һәм утырыш тәмамланганнан соң комиссия секретарена кире кайтарылырга тиеш.

40. Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең булуы һәм комиссия утырышларында кино-, видео- һәм фотога төшерү, шулай ук тавыш яздыру комиссия рәисе яки аның кушуы буенча, комиссия секретаре тарафыннан билгеләнгән тәртиптә оештырыла.

41. Комиссия утырышларында комиссия рәисе карары буенча стенографик язма һәм утырышның аудиоязмасы алып барыла.

42. Утырышта катнашучыларга һәм чакырылган затларга утырышка кино-, видео- һәм фотоаппаратураны, тавыш яздыру җайланмаларын, шулай ук элемтә чараларын алып килергә рөхсәт ителми.

## 5 бүлек. Комиссия утырышларында кабул ителгән карарларны рәсмиләштерү

43. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырышны үткәрү датасыннан соң ун көн срокта комиссия секретаре тарафыннан әзерләнә һәм комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

44. Комиссия карарында комиссия утырышын үткәрүче затның һәм утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының, чакырылган затларның фамилияләре, утырыш барышында каралган мәсьәләләр, кабул ителгән карарлар күрсәтелә.

45. Комиссия утырышында каралган, тәкъдимнәр һәм кимчелекләр әйтелгән проектларны эшләп бетерү кирәк булган очракта, комиссия карарында комиссия әгъзаларына тиешле йөкләмә чагылдырыла.

46. Комиссия карарлары (комиссия карарларыннан өземтәләр), имзаланган карар комиссия тарафыннан алынганнан соң өч көн срокта, аларга кагылышлы өлештә, Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының , Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының бүлекчәләренә, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына җибәрелә, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар игътибарына җиткерелә.

47. Комиссия карарларында булган карарларның һәм йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тотуны комиссия секретаре гамәлгә ашыра.

Комиссия секретаре комиссия рәисе карары нигезендә йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдән төшерә, бу хакта башкаручыларга хәбәр итә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреева

Шәһәр Хакименең
2017 елның 26 сентябрендәге
М 363 номерлы карарына
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
террорчылыкка каршы комиссиясе
составы

| № | Ф.И.А.и. | вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Мәһдиев<br>Наил Гамбәр улы | комиссия рәисе, шәһәр Хакиме |
| 2. | Галиәкбәров<br>Сирень Фатыйх улы | комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы буенча Федераль куркынычсызлык хезмәте идарәсе башлыгы урынбасары, Яр Чаллы шәһәрендәге хезмәте башлыгы (килешү буенча) |
| 3. | Фәйсханов<br>Рамил Рәшит улы | комиссия секретаре, шәһәр Хакиме ярдәмчесе (коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча) |
| комиссия әгъзалары: | | |
| 4. | Абдуллин<br>Ринат Әзһәр улы | Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 5. | Андреева<br>Флера Ивановна | муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары |
| 6. | Әхмәтова<br>Гөлнар Карл кызы | Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе |
| 7. | Бариев<br>Илгизәр Габделхалик улы | Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт идарәсенең территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 8. | Галимов<br>Искәндәр Нургаләм улы | Башкарма комитетның Үзәк район Хакимияте Башлыгы |
| 9. | Закиров<br>Надир Дамир улы | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| 10. | Зыятдинов<br>Рафаил Хафиз улы | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча ТР ГТХМ идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| 11. | Зуев<br>Илья Сергеевич | Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 12. | Ильясов<br>Рәшит Флүр улы | Яр Чаллы шәһәренең Үзәк һәм Автозавод районнары буенча ТР Хәрби комиссариаты бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 13. | Кыямов<br>Рафаил Әгъләметдин улы | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 14. | Мингалиев<br>Рәүф Минрәхим улы | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| 15. | Мөхәммәтҗанова<br>Римма Равил кызы | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе башлыгы |
| 16. | Ногманова<br>Эльвира Илшат кызы | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| 17. | Усманова<br>Раушан Мәсгут кызы | Башкарма комитетның Автозавод районы Хакимияте башлыгы |
| 18. | Хәлимов<br>Рамил Мәрван улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары

Ф.И. Андреева